**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Түбән Кармалка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены карары**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**Түбән Кармалка авыл җирлегенең**

Чумачка авылы
08 ноябрь 2019 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлегендә гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2020 елда Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш.
2. Алынган чараларны җибәрергә:

- Чумачка торак пунктында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр, трактор арбасы сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;
- Чумачка торак пунктында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Чумачка торак пунктында чишмәләрне төзекләндерү югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу.

Халык җыенында рәислек итүче
Түбән Кармалка авыл җирлеге
Башлыгы Урынбасары: Е.Н.Денисова